# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ЯМБАКТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

28.04.2021ел №20

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2009 елның 11 сентябрендәге 63-2 номерлы карары (2020 елның 22 сентябрендәге 2 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федеральз аконның 31 статьясы нигезенд һәм Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципальрайонының Ямбакты авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 11 сентябрендәге 63-2 номерлы карары (2020 елның 22 сентябрендәге 2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 2.2.пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда унтугыз яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган җирлек я исә аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.".

1.2. Нигезләмәнең 7 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«7. Сораштыру үткәрү инициативасы.

7.1. Гражданнарны сораштыру инициатива буенча үткәрелә:

1) җирлек Советы яисә җирлек башлыгы-җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Россия Федерациясе субъектларының дәүләтхакимияте органнары – Региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар өчен урнашу җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнарның фикерен исәпкә алуөчен;

3) җирлектә яшәүчеләрнең я исә аның өлешенең уналты яшькә җиткән инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган өлешләрендә гражданнарның әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау өчен.

7.2. Җирлек башлыгы инициативасы белән сораштыру үткәрелгәндә соңгысы Җирлек Советына тиешле мөрәҗәгать белән чыга.».

2. Әлеге карарны Ямбакты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы: И.Э.Галэветдинов..